СОВЕТ ЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Новая, д.9, с. Нижние Яки
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422157

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Яңа ур., 9 нче йорт, Түбән Яке авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422157

тел.(факс): (85563) 2-94-38; e-mail: Yak.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение　　　　　　　　Карар

от “17” ноябрь 2020 ел　　　　　　　　№4-2

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 14 октябрендәге №2-48 карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 1 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 14 октябрендәге № 2-48 карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1 1.7 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан инициатив проектларны күрсәтү, әзерләү, сайлап алу һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча гамәлгә ашырыла торган җирлектә»;

1.2 3.3 пунктта «теркәлә һәм кертелә» сүзләрен « керү рөхсәт ителә» сүзенә алмаштырырга;
1.3 4.2 пунктта «җирлек башлыгы» сүзләреннән соң «яисә башка рәислек итүче зат» сүзләрен өстәргә;
2. Әлеге карарның 1.1 пункты 2021 елның 1 гыйнвареннән гамәлгә керә.
3. Әлеге карарны Яке авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарның үтәлеше буенча җаваплылыкны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Яке авыл җирлеге Башлыгы урынбасы __________ Ф.Г.Насибуллин